КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 сентябрь г.Казань № 1200

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турында, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты хакында» 2023 ел, 15 сентябрь, 1136 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турында, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты хакында» 2023 ел, 15 сентябрь, 1136 нчы карарына, түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$4^1$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турында» 2008 ел, 28 март, 206 нчы карары белән расланган Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты

проектын һәм Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турындагы нигезләмәнең 15, 16, 21 һәм 22 пунктларында каралган сроклар 2023 елда кулланылмый дип билгеләргә.»;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин